**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5011**
**07.09.2018**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсенең 1 бүлегендәге 4 пункты, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 7 сентябрендәге
5011 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 398,05 |
| 2. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 7,96 |
| 3. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 548,85 |
| 4. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 10,98 |
| 5. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 1207,06 |
| 6. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 24,14 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова